**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АНДРЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Андреевка ав. **КАРАР**

«20» декабря 2022 г. № 14

**2023 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 25.07.2002 ел, № 114-ФЗ Федераль закон, «террорчылыкка каршы тору турында» 06.03.2006 ел, № 35-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә 19.12.2012 ел № 1666 «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында», «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән һәм җирлек чикләрендә экстремистик һәм террорчылык эшчәнлеген кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар күрү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендына һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Бу карар бастырылганнан бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Андреевка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.И. Егорова

Андреевка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 20
декабрендәге 14 номерлы
карарына кушымта

**2023 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планы**

| № т/с | Чаралар атамасы | Башкаручылар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Террорчылык характерындагы янаулар килеп чыккан очракта гражданнарның массакүләм булган урыннарында гамәлләр турында мәгълүмат материаллары урнаштыруны тәэмин итү, шулай ук тиешле мәгълүматны стендларда урнаштыру | Җирлек башлыгы | даими |
| 2 | Шикле предметларны, шартлаткыч җайланмаларны ачыклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалауны тәэмин итү; мәгълүмат таблицаларын, белешмәлекләрне ясау һәм тарату | Җирлек башлыгы | Квартал саен |
| 3 | Экстремизмга каршы тору буенча белешмәлекләр, методик күрсәтмәләр тарату. | Гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | даими |
| 4 | Экстремизм, терроризм, шәхес, җәмгыять, дәүләткә каршы җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән гражданнар җыеннарында лекцияләр һәм әңгәмәләр уздыру | Җирлек башлыгы, полициянең участок уполномоченные (килешү буенча) | Квартал саен |
| 5 | Җирлек территориясендә урнашкан мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрендә төрле халыкларның һәм милләтләрнең гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләү максатыннан тематик чаралар, конкурслар, викториналар оештыру һәм уздыру | Авыл җирлеге башлыгы, мәдәният йорты мөдире, мәктәп директоры, китапханәче (килешү буенча) | Ел дәвамында |
| 6 | Авыл җирлеге территориясендә буш йортларны тикшерү | Җирлек башлыгы, полициянең участок уполномоченные (килешү буенча) | Ай саен |
| 7 | Торак биналарны арендага бирүче затларны һәм теркәлмичә генә торак урыннарда яшәү фактларын ачыклау | Җирлек башлыгы, полициянең участок уполномоченные (килешү буенча) | даими |
| 8 | Терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көнен оештыру һәм үткәрү | Авыл җирлеге башлыгы, депутатлар, | 3 сентября |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мәдәният йорты мөдире, мәктәп директоры (килешү буенча) | |
| 9 | Террорчылык актлары куркынычы һәм экстремистик материаллар тарату турында белә торып ялган хәбәрләр өчен җаваплылыкны аңлату максатыннан гомуми белем мәктәпләре укучылары арасында профилактик эш оештыру һәм үткәрү | Җирлек башлыгы, мәктәп директоры, полициянең участок уполномоченные (килешү буенча) | апрель, сентябрь |
| 10 | Экстремизм, терроризм, шәхес, җәмгыять, дәүләткә каршы җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән китап күргәзмәләрен оештыру | Китапханәче (килешү) | Ел дәвамында |
| 11 | Халыклар бердәмлеге көнен бәйрәм итү кысаларында чаралар оештыру һәм уздыру | Авыл җирлеге башлыгы, мәдәният йорты мөдире, мәктәп директоры, китапханәче (килешү буенча) | 4 ноября |
| 12 | Татарстан Республикасы Конституциясе көненә багышланган чаралар оештыру һәм уздыру | Мәктәп директоры (килешү буенча) | ноябрь |
| 13 | Россия Федерациясе Конституциясе көненә багышланган чаралар оештыру һәм уздыру | Мәктәп директоры (килешү буенча) | декабрь |
| 14 | Экстремизм һәм терроризмны профилактикалау буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген билгеләү максатларында халык арасында социологик сораштырулар үткәрү | Җирлек башлыгы | ноябрь |